**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 октябрь № 768

г. Казань

2017/2018 уку елына һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 / 2018 уку елына түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016/2017 уку елына һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәре нормативларын һәм норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 18 ноябрь, 873 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2017 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 20 октябрь, 768 нче
карары белән расланды

Һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын –
Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Белем алу вакыты, ай | Бер белем алучыга эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, 1 елга сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җире | авыл җире |
| 15.01.26 | Токарь-универсал | 6 | 11 563 | 13 443 |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 6 | 14 452 | 17 003 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 4 | 6 892 | 7 958 |
| 15.01.05 | Эретеп ябыштыручы (электр белән эретеп һәм газ белән эретеп ябыштыру эшләре) | 6 | 14 292 | 16 803 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 20 октябрь, 768 нче
карары белән расланды

Һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

**КҮЛӘМНӘРЕ**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күрсәтү күләме нормативы, белем алучылар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 15.01.26 | Токарь-универсал | 15 |
| «Чистай күппрофильле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 25 |
| «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 25 |
| «Баулы аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| «Саба аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 25 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| «Спас тармак технологияләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 15.01.05 | Эретеп ябыштыручы (электр белән эретеп һәм газ белән эретеп ябыштыру эшләре) | 20 |
| «Нурлат аграр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 25 |
| «Кукмара аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 25 |

_______________________________________